ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 02.06.2026 | г. Иннополис | 30 |

«Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
«Иннополис шәһәре» муниципаль
берәмлегенең торак комиссиясен
төзү турында» 11.12.2025 ел № 100
Иннополис шәһәре Башкарма
комитеты карарына 11.03.2026 ел
№ 8 үзгәрешләр белән
редакциядә үзгәрешләр
кертү хакында

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 27.12.2004 ел, № 69-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.04.2005 ел, № 190 карарына таянып, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең торак комиссиясен төзү турында» 11.12.2025 ел, № 100 карарына 11.03.2026 ел, № 8 үзгәрешләр белән редакциядә (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 нче кушымтасында комиссия секретаре вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Иннополис шәһәре Башкарма комитетының хокукый ярдәм бүлегенең юридик эш буенча баш белгече".

1.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең торак комиссиясе турындагы нигезләмәнең карарга 2 нче кушымта булып торган 4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Комиссия секретаре гражданнарны исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен барлык кирәкле документларны әзерли. Секретарь булмаган очракта (шул исәптән отпуск, авыру, командировка яисә вазыйфаларны үтәүгә комачаулый торган башка хәлләр аркасында) аның вәкаләтләре вакытлыча торак комиссиясе

әгъзаларының берсенә — утырышта торак комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышлары кабул иткән карар нигезендә йөкләнә».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Я. Н.Елистратовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ф. Ханбиков